«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы
КАРАРЫ

2021 елның 22 гыйнвары №22

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 18 декабрендәге 93 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2016 елның 09 сентябрендәге 31 номерлы карары редакциясендә)

Җирләрне кирәгеннән артык ваклауны оптималь файдалану һәм төшереп калдыру, гражданнарны җир кишәрлекләре белән тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкны үстерү максатларында, шулай ук, Россия Федерациясе Җир кодексына, Татарстан Республикасы Җир кодексына, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 07 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

56 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле бүлек өстәргә: гражданнарга дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән арендага яисә милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләмнәрен билгеләргә:

а) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен:

- торак пункт чикләрендә (йорт янындагы җир кишәрлеге) - 0,1 гектардан 0,15 гектарга кадәр,

- торак пункттан читтә (кыр җир кишәрлеге) - 0,1 гектардан 1,0 гектарга кадәр;

б) индивидуаль торак төзелеше өчен 0,1 гектардан 0,15 гектарга кадәр.

2. Әлеге карарның 2 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) үлчәмнәре гражданнарга әлеге карарның үз көченә рәсми кергәннән соң бирелә торган җир кишәрлекләренә (яңа бүлеп бирелә торган җир кишәрлекләренә) кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 2 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләмнәренең әлеге карарны кабул иткәнче гражданнарга аренда хокукларында бирелгән һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә алар тарафыннан сатып алына торган җир кишәрлекләренә кагылмавын билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы

поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 22 номерлы карарын «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау хакында» 2013 елның 18 декабрендәге 93 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга (2016 елның 9 сентябрендәге 31 номерлы карар редакциясендә)

5. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Кама Тамагы штп, Совет ур., 11й., (административ бина);
- Кама Тамагы штп, К. Маркс ур.,105 й. (китапханә бинасы),

шулай ук әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Дәүләтшин Раил Хәмит улына йөкләргә.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге Башлыгы ,
«Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы
поселогы» муниципаль берәмлеге Советы рәисе Н.А.Вазыйхов